Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

РЕШЕНИЕ КАРАР

25.08.2020 Менделеевск ш. №273

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
территориясендә җирләрдән файдалануга
муниципаль җир контроле турында Нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

РФ Җир кодексының 72 статьясы нигезендә, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының 2018 елның 26 июнендәге 154 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә җирләрдән файдалануга муниципаль җир контроле турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3.16. пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында гражданнарга карата тикшерүләр документар һәм (яки) күчмә рәвешләрдә үткәрелә, аларның һәркайсын үткәрү вакыты 20 эш көненнән дә артмаска тиеш.

Катлаулы һәм (яисә) озак вакытлы тикшеренүләр, махсус экспертизалар үткәрү зарурлыгына бәйле аерым очракларда тикшерү уздыручы затларның дәлилләнгән тәкъдимнәре нигезендә тикшерү срогы муниципаль җир контроле органы җитәкчесенең (җитәкче урынбасарының) күрсәтмәсе (боерыгы) белән озайтыла, әмма ул 20 эш көненнән артмаска тиеш.»;

1.2. Нигезләмәнең 1 бүлегенең 3.17 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үткәрү срогы: юридик затка, индивидуаль эшкуарга күчмә яисә документар тикшерү уздыруның гомуми срогы – кече эшкуарлык субъектлары өчен законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, егерме эш көненнән дә артмый,

Катлаулы һәм (яки) озак вакытлы тикшеренүләр уздыру зарурлыгына бәйле аерым очракларда, муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының күчмә планлы тикшерү үткәрә торган мотивлаштырылган тәкъдимнәре нигезендә, күчмә планлы тикшерүне үткәрү вакыты мондый орган җитәкчесе тарафыннан озайтыла, ләкин егерме эш көненнән дә артык түгел, кече предприятиеләргә карата илле сәгатьтән дә артык түгел, микропредприятиеләргә карата ул унбиш сәгатьтән дә артмаска тиеш.»;

Нигезләмәнең 1 бүлегендәге 3.18 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тикшерү нәтиҗәләре буенча палатаның вазыйфаи заты тарафыннан тикшерү үткәрелгән көнне 141 номерлы боерык белән билгеләнгән форма буенча акт төзелә».

2. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.ru «Норматив документлар» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Совет Рәисе В.С.Чершинцев